КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 29 декабрь г.Казань № 1437

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәр күләмнәренең план күрсәткечләрен һәм әлеге керемнәрдән (максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш) эш хакын түләүгә җибәрелә торган чыгымнарның тәкъдим ителә торган күләмнәрен билгеләү турында» 2021 ел, 13 декабрь, 1212 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәр күләмнәренең план күрсәткечләрен һәм әлеге керемнәрдән (максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш) эш хакын түләүгә җибәрелә торган чыгымнарның тәкъдим ителә торган күләмнәрен билгеләү турында» 2021 ел, 13 декабрь, 1212 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 3 июнь, 518 нче, 2022 ел 21 ноябрь, 1251 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

$1^1$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$1^1$. Түләүле хезмәтләр күрсәтүдән керемнәр күләменең планлы күрсәткечләреннән арткан Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләре тарафыннан алынган түләүле хезмәтләр күрсәтүдән керемнәр күләме, шул исәптән акчалары максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш, алар тарафыннан «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тиешле финанс елына Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр

күрсәткәндә план күрсәткечләрен формалаштыру тәртибе турында» 2017 ел, 21 сентябь, 705 нче карары белән расланган Тешле финанс елына Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәткәндә план күрсәткечләрен формалаштыру тәртибе нигезендә билгеләнә торган күләмдә хезмәт хакы түләүгә җибәрелә дип билгеләргә.»;

3[1] пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«түләүле хезмәтләр күрсәтүдән керемнәр күләменең планлы күрсәткечләреннән арткан тәкъдим ителгәннән артык алынган түләүле хезмәтләр күрсәтүдән керемнәр күләме, шул исәптән акчалары максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш, әлеге карарга 2 нче һәм 3 нче кушымталарда билгеләнгән «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тиешле финанс елына Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәткәндә план күрсәткечләрен формалаштыру тәртибе турында» 2017 ел, 21 сентябь, 705 нче карары белән расланган Тешле финанс елына Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәткәндә план күрсәткечләрен формалаштыру тәртибе нигезендә билгеләнә торган күләмдә хезмәт хакы түләүгә җибәрергә;»;

әлеге карарга теркәлгән 1 нче кушымтада:

4 нче графада:

«Барлыгы» юлында «1 653 670,0» саннарын «1 653 550,0» саннарына алмаштырырга;

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы» юлында «1 800,0» саннарын «1 680,0» саннарына алмаштырырга;

әлеге карарга теркәлгән 2 нче кушымтада:

4 нче графада:

«Барлыгы» юлында «4 992 987,0» саннарын «4 867 980,0» саннарына алмаштырырга;

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы» юлында «3 449 443,0» саннарын «3 324 436,0» саннарына алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин